ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясындагы $2^1$ өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$2^1$. Бала бертуганнары һәм атасы йә анасы башка булган абыйсы һәм (яисә) апасы укый торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә белемнең һәм башлангыч гомуми белемнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга өстенлекле кабул ителү хокукына ия.».

**2 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендәге $15^3$ пунктында «максатчан укыту турындагы шартнамәнең якларын» сүзләрен «максатчан укытуга заказ бирүчене» сүзләренә алмаштырырга;

2) 14 статьяның $2^1$ өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$2^1$. Бала бертуганнары һәм атасы йә анасы башка булган абыйсы һәм (яисә) апасы укый торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә белемнең һәм башлангыч гомуми белемнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга өстенлекле кабул ителү хокукына ия.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 74-ТРЗ